Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Нәҗәр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**16.11.2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның "18" ноябрендә 12 сәгать 00 минутта уткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: "2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нәҗәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Нәҗәр авылы юлы өчен вак таш сатып алу һәм җәю).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнарның 57 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 33 кеше, бу 58 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 33 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нәҗәр торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. I төркем инвалидларыннан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ихтыярый затлар) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар), ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, 2024 елда Тирсә авыл җирлеге территориясенең Нәҗәр авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Нәҗәр авылы юлы өчен вак таш сатып алу һәм җәю).

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы И. Б. Гыйззәтуллин